ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**БОЕРЫК**

29.03.2018 | Казан шәһәре | №38-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарны үтәүне тикшереп торуны көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 19 сентябрендәге № 431 Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 11 декабрендәге № ПУ-1092 Указы басылып чыгуга бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карат таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карат таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 18.01.2017 № 006-од боерыгы белән расланган нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 3.4.3. пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«3.4.3.п. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4 һәм 3.4.1. пунктлары белән каралган дәлилләнгән бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдәге һәм хәбәрнамәләрдәге мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынучы оешмалардан гарызнамәләр нигезендә алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә карарларның берәрсен яисә бүтән карар кабул итү өчен рекомендацияләр».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова